## ТӨРЛЕСЕННӘН

# *Туган җире аңа көч бирә*

**Соңгы 15-20 ел эчендә телевизордан күрсәтелгән, газета-журнал битләрендә басылган язмаларны укыганда чәчләр үрә тора. Күпме артист, спортчы, урлашып баеган түрә-депутатларның тормышларын яктырткан мәкаләләр, сюжетлар урын ала аларда! Җиде-сигез ир алыштырган, биш-алты хатын белән яшәгән, үз халкын талаган кешеләрнең пычрак тормышлары нинди тәрбия бирә торгандыр?.. Кызганыч... Гайбәт ятаручылар күбәйгәнме әллә?..**




Уңган завод эшчеләре, мул уңыш үстергән игенчеләр, үз хезмәтләренең осталары булган укытучылар, табиблар һәм башка һөнәр ияләре турындагы мәкаләләр ни өчен аз? Хезмәтнең дәрәҗәсе төштеме әллә? Аллага шөкер, яраткан газетам “Шәһри Чаллы”га бу чир эләкмәде. Аның битләрендә үз гамәлләре белән халык хөрмәтенә лаек булганнар хакында язалар. (Үзем бу газетаны чыга башлаганнан бирле алдырам һәм бер генә тапкыр да аңа хыянәт иткәнем булмады.)

Менә бүген мин дә якташым Гамил Афзал күк туры сүзле, тормышындагы киртәләрне җимереп алга баручы, үзенең мәрхәмәтле эш-гамәлләре белән башкалар күңеленә өмет уты кабызучы шәхес турында язарга булдым әле. Бу кешенең “Аллабирде” тәхәллүсе (псевдонимы) астында бастырылган шигырь-хикәяләрен 80 нче еллар ахырыннан ук укып барсам да, үзе белән шактый соң таныштым. 1997 елдан “Идел-Урал” хәйрия фонды җитәкчесе вазыйфасын башкарган Рәкит Җәүдәт улы Әбделмәнов кул көрәштерү буенча күп тапкырлар җиңүче булган кеше дә икән әле. Өстәл теннисы, ат спорты өлкәсендә дә уңышлары җитәрлек. “Аллабирде” дигән беренче китабы 1996 елда басылган. Берничә көн элек кенә шәһәребезнең Үзәк китапханәсендә Рәкитнең Казан китап нәшриятында басылган “Сулыш” китабын тәкъдир итү кичәсе булып узды. Мондый очрашуларны әдәбият тарихы музееның җитәкчесе Роза Хәмидуллина искиткеч осталык белән алып бара. Кичәгә китап сөючеләр, “Ләйсән” иҗат берләшмәсе әгъзалары килгән иде. Яңа китап турында язучы Мансур Сафин, Рушания Гыйләҗева, Әлфия Габдерәшитовалар үз фикерләрен әйттеләр, авторга үзләрен кызыксындырган сорауларын бирделәр. Кичәне автор-башкаручы Зөлфия Җиһан моңлы җырлары белән бизәде. Ул җырларның сүзләрен дә Рәкит язган булып чыкты. Шәһәребезнең төзелешенә зур өлеш керткән Рафаэль Имамовның гармунда башкарган көйләре дә күңелләргә хуш килде. Рафаэль әфәнде, Рәкит Әбделмәновтан үрнәк алып, сәләтле шахматчы балаларга ярдәм итү фонды төзү белән шөгыльләнүен әйтте. Яхшы үрнәк әйбәт нәтиҗәләр бирсен! Менә шундый матур кичәләр күбрәк булсын!

**Зәбир ХӘЛИМОВ**